# КОРБАН ГАЕТЕ

Тимерле зур ишекнең шылтырап ачылуына, Муса әфәнде уянып китте. Ул, үзен белмәгән кебек, үзенең кая икәнлеген оныткан кебек, камерасының стеналарына карый башлады. Камерасының түшәмен, стеналарын карап бетергәннең соңында, әллә нәрсә эзләгән кеше кебек, ишеккә күзен салды. Ишек төбендә басып тора торган револьвер таккан надзиратель аның уянганын белеп: «Господин Әхмәтов, бәйрәмнәр мөбарәк булсын!» — диде.

Муса әфәнде надзирательнең бу сүзен элгәре аңламаган булса да, ахырдан бу көн корбан бәйрәме идеке, төнә төн буе мөселман арестантлар гаеткә барырга хәзерләндеге хәтеренә килде.

Муса әфәнде бу сүздән, бик озын йокыга киткән кебек яисә бер-бер нәрсәдән куркып бердән катып киткән кеше кебек булып, диварның бер йиренә күзен тегәп уйларга тотынды. Аның күз алдына үзен белә башлаганнан бирле үткәргән бәйрәмнәре килә башлады. Ул үзенең үз авылларында ничек итеп гает үткәргәннәрен, бәйрәмнәрдә ничек кызык булганлыкларын хәтеренә китерә башлады. Ул үзенең төрмәдәлеген онытып, үзенең татлы фаразына бөтенләй чумды. Менә аның күз алдына әллә никадәр өелгән кешеләр килгән кебек, аның колагына әллә ничә йөз авыздан чыккан тәкбир тавышы ишетелгән кебек була башлады. Ул үзенең үзе кебек малайлар берлә яңа күлмәк, яңа казакиләр киеп, әнисенең гатырша маена сөртенеп, этисе биргән акчага кесәсендә чикләвек тутырып, элгәре бабаларына барып, коймаклар, беленнәр берлә чәй эчүләрен, аның соңында абзыйларына барып, тагы кыстыбый, пәрәмәчләр берлә сыйланып, аның артыннан күршеләренә, дустларына барып, тагы шундый сыйлар күрүен, кайсыларыннан майлы коймаклар, чәкчәкләр, акчалар алып чыгуларын исенә төшерде. Шул көнне малайлар берлә төрле уеннар уйнаулары бөтен урам малайлары берлә киемнәрен чагыштырып мактанышулары хәтеренә килде. Аннан соңгарак, мәдрәсәдә укый башлагач, бәйрәмнәргә шәһәрдән кайтулары, кайтканда этисе-энисе, агае-энесе, үзенең дуст малайларын күрдем дип шатланулары,

кайткач ук чәй эчәр-эчмәс үзенең дустларына барып, аларга мәдрәсәне, шәһәрне сөйләүләре, алар берлә әллә нинди уеннар уйнавы, иртәгесен зур кешеләр артыннан тәкбир әйтеп барулары, мәсҗедтә һәр кешенең кесәләрен актарып сәдака бирүләре, муллаларның шалтыр-шолтыр бакыр акчаларны җыюлары, мөәззиннең ялгыша-ялгыша гает ниятләре өйрәтүе, мулланың сузып-сузып, беркем дә аңламаган телдә хотбә укуы, гаеткә барган кешеләрнең мыш-мыш йоклаулары, өйгә кайтып чәй эчүләре, корбан чалулары, муллаларга тиресен илтергә барулары бүгенге эш кебек күз алдына килә башлады. Зурая төшкәч, шәһәрдә вакытта гает көннәрендә иптәшләренә, дустларына бәйрәм котларга барулары, дустлары берлә җыелышып, гостиницаларга барып рәхәтләнеп сөйләшеп утырулары, читтәге дустларыннан, иптәшләреннән тәбрик хатлары алуы исенә төште. Ул бүген дә шулайдыр, бүген дә халык төркем-төркем тәкбир әйтеп мәсҗедкә баргандыр, бүген дә гаеттән соң һәркем өйләренә кайтып, бөтен җәмәгате берлә гөрләшеп чәй эчкәндер, бүген дә корбаннар чалганнардыр, бүген дә һәр өйдә әллә никадәр ашамлык-эчемлекләр хәзерләп, бәйрәм котлаучыларны көтә торганнардыр, бүген дә әллә никадәр атларда яхшы киемнәрдән картлар вә яшьләр бәйрәм котлап йөри торганнардыр. Бүген дә һәммәсенең йөзләре ачык, һәммәсенең күңелләре шаттыр дип, аның да шул шатлыклар берлә шатланасы, шул кешеләр кебек мәгънәсез котлаулар артыннан йөрисе, шул кешеләр кебек өйдән-өйгә кереп, көненә кырыгар чынаяк чәй эчеп йөрисе килде. Аның да шулар кебек вак-төяк шәһәр хәбәрләрен сөйләп, яңа чыккан китаплар тугрысында мөхакәмә кылып, үзенең эшен онытып, үзенең кайгысын, үзенең хәсрәтен күңелдән чыгарып йөрисе килде. Аның да үзенең төрмәдәлеген, үзенең бер елдан бирле төрмәдәлеген, үзенең тагы, белмим, никадәр төрмәдә торачагын онытып, шул кайнаган халык дәрьясына чумасы, кешеләр берлә сөйләшәсе, иптәшләре берлә көлешәсе, уйнашасы килде. Әллә кайчаннан бирле күрә алмаган иптәшләренең кулын кысып-кысып күрешәсе, үзенең төрмәдәниләр күргәнен, бөтен халык иректә торганда, үзенең тар, тыгыз, сасы бүлмәдә бикләнеп ятканын, үзенең төрмәдә вакыттаниләр уйлаганын сөйлисе

килде. Иректә бәйрәмнәр ясап ятканда, иректә һәр өйдә ашамлык-эчемлек күплектән өстәлгә чынаяк куярга урын юк вакытта, үзенең ачлы-туклы торуын, шул бәйрәм итә торган, шул шатлык дәрьясында гизә торганнарның правасы, рәхәте өчен тырышып йөргәндә, иректән мәхрүм калып, үзенең төрмәдә ятуларын аңлыйсы килде. Халык өчен никадәр каһарманлык кылса да, халык юлында никадәр мәшәкать чиксә дә, иректәге беркемнең дә моның хакында кайгырмавы, моның тормышын рәтләр өчен тырышмавы өчен шул бәйрәмчеләр берлә сүгешәсе, аларны оялтасы килде. Аларның оятсызлыкларын, аларның инсафсызлыкларын йөзләренә бәрәсе килде. Тагы күзе ишеккә төште. Тагы үзенең төрмәдәлеге, үзенең иректәге кешеләр кебек бәйрәм ясарга хакы юклыгы хәтеренә килде, үзенең шул бәйрәмне, бәлки тагы шундый бәйрәмне төрмәдә үткәрергә мәҗбүр булуы күңеленә килде. Үзенең тиз чыгулары, тиздән кеше кебек йөрү өметләре бетте. Шул өмет берлә бергә аның матур фаразлары, үзенең яшь гомерен уйлаулары да әллә кая югалды. Аның күз алдына әллә нинди ямьсез манзарәләр күренә башлады. Үзен-үзе, богауланган көенчә, каторгага җибәрелгәнен күргән кебек була башлады. Фикерләр ямьсезләнгәннән ямьсезләнде, аның йөрәге сикерә башлады, битләре яна башлады, тамагына әллә ни тыгылган кебек булды, күзеннән кайнар яше ага башлады.

Бәйрәм үтте.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Иту* – илтү.
*Мөхакәмә* – сөйләп тикшерү, бәхәс кылу.

***Корбан гаете*** — Хикәя беренче тапкыр «Тавыш» гәзитәсенең 1907 ел, 23 апрель (1) санында басылган. «Фельетон» дип куелган. Имза: Гаяз. Г.Исхакыйның «Җыентык» (1909) исемле китабына кертелгән.

Авторның 1907 елда Чистай төрмәсендә язылган «Зиндан» повестенда бу хикәянең язылу тарихы китерелә. Гает көне якынлаша. Сәяси тоткыннар гаеткә мәчеткә алып баруларын сорап Жандарм идарәсенә мөрәҗәгать итәләр. Үтенеч кире кагыла. Бу уңай белән Г.Исхакый повестьта болай ди: «Гает җитте. Мөселман арестаннарын мәсҗедкә алып киттеләр. Алар кайсы ат урлаган гына булганга, кайсысы кеше генә үтергәнгә, кайсысы кибет кенә басканга, безнең кебек үк куркыныч түгелләр иде». Хикәядә Мусаның кичерешләрендә олуг бәйрәм көнендә авторның үзенең төрмәдәге кичерешләре чагыла.

Г.Исхакый бу хикәясен кичәләрдә дә укыган. Матбугатта Казандагы бер әдәбият кичәсе турындагы мәкаләдә: «Сәгыйть әфәнде «Курчак туе»ны укымыш... «Корбан бәйрәм»ен («Корбан гаете»н,— Л.Г.) Гаяз укымыш... диелә. *(Әдәбият кичәсе — Вакыт. 1907, 10 апр.)*

Текст «Җыентык»тан алынды.

*Корбан гаете* — мөселманнарның дини бәйрәме. Бәйрәм Зөлхиҗҗә аеның (һиҗри елның 12 нче ае) 9—13 көннәрендә уздырыла. Корбан чалуның да үз тарихы булган. Ривайәтләргә караганда, Ибраһим пәйгамбәр Аллаһе Тәгаләгә чиксез бирелгәнлек билгесе итеп үзенең улы Исмәгыйльне корбан итәргә әзер булуын белдергән. Ләкин Алла кодрәте белән аның алдына корбанга сарык килеп баскан. Бу вакыйга Коръәннең 37 нче сүрәсендә (97—110) һәм хәдисләрдә тасвирлана. Корбан өчен сарык, кәҗә, сыер һәм дөя кебек пар тояклы хайваннар тәкъдим ителә. Бер генә тояклы булганга, ат рөхсәт ителми.

*Хотбә* — җомгада һәм дини бәйрәмнәрдә мәчеттә укыла торган намазларда дин тотучыларга мөрәҗәгать итеп имам тарафыннан сөйләнә торган вәгазь.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б. 19-21.